Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Советы

КАРАР №3-1

Бәтке авылы 2022елның 17 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2013 елның 3 сентябрендәге "Бәтке авыл җирлеге территориясендә җирләү һәм мәет күмү урыннарын карап тоту (тору) кагыйдәләре турында"гы 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында,"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 30 апрелендәге 119-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Уставының 32 маддәсендәге 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2013 елның 3 сентябрендәге "Бәтке авыл җирлеге территориясендә җирләү һәм мәет күмү урыннарын карап тоту (тору) кагыйдәләре турында"гы 10 номерлы карарының 1.4 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәп үзгәреш кертергә:

"Ватанны саклаганда һәлак булучылар күмелгән урыннар хәрби каберлекләр буларак "Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү турында" 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары карары буенча гына күчерелергә мөмкин".

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы, Ленин урамы, 4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контроль итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов